# КАРАР

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы
Шәңгәлче авыл җирлеге составына керүче Шәңгәлче авылы гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

2020 елның 11 декабере № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 11 декаберендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Шәңгәлче авыл җирлеге Шәңгәлче авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 150 сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Әлеге сумманың 50% ы күләмендә 2 төркем инвалидлар түли. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- Шәңгәлче авылының юлларын төзәтү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 479 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 245 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 220 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 25 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге составына керүче Шәңгәлче авылы гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.

2. «Түбән Кама муниципаль районының Шәңгәлче авыл җирлеге Шәңгәлче авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 150 сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Әлеге сумманың 50% ы күләмендә 2 төркем инвалидлар түли.

һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- Шәңгәлче авылының юлларын төзәтү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Шәңгәлче авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Шәңгәлче авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Сәлимов